СОВЕТ
БИЛЯРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БИЛӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2019 с. Билярск № 113

**Алексеевск муниципаль районы**
**Биләр авыл җирлеге советының**
**16.11.2018 ел 81 нче номерлы**
**“Физик затлар милкенә салым турындагы”**
**карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында,шул исәптән» Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү турында «2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 79 пунктының " б " пунктчасы» ,"Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 15 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль законның 28 пунктындагы «б" пунктчасы һәм "Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә һәм салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль законның 9 статьясы»нигезендә

**Биләр авыл җирлеге советы карар итте:**

1. Алексеевск муниципаль районы Биләр авыл җирлеге советының 16.11.2018 ел 81 нче номерлы “Физик затлар милкенә салым турындагы” карарына түбәндәге эчтәлекле үзгәрешләр кертергә:

4 нче пунктның 9 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
« Салым ташламасы бирелә торган сайлап алынган салым объектлары турында хәбәрнамә,салым түләүче тарафыннан салым органына салым чоры булып торучы елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча бирелә, шуның белән әлеге объектларга карата салым ташламасы кабул ителә.

Сайланган салым салу объектлары турында хәбәрнамә салым органына дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша тапшырылырга мөмкин».

2. Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан, әмма Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында рәсми басылып чыккан көннән ,бер айдан да иртә булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» “Интернет “мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы җирлек сайтында урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Биләр авыл җирлеге Советы бинасында махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткеререгә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Биләр авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Г.Г. Хәбибуллин**